ГЛАВА ОКТЯБРЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ОКТЯБРЬСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11.10.2022 пос. Октябрьский 05

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Ключищи авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003нче елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56нчы статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35нче статьясына, Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге Уставынаың 24 ст. туры китереп,

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Ключищи авылы гражданнары үзара салым кертү мәсьәләсе буенча 2022 елның 27 октябренә гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
   «2023 елда Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Ключищи авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару буенча алынган акчалар юлламасы белән килешәсезме:
   - Ключищи авылында су белән тәэмин итү системаларын төзү һәм ремонтлау
   «ӘЙЕ» «ЮК»
3. Ключищи ав., Колхозная ур., 95 йорт адресы буена к ибет бинасы янында 10.00 сәг.халык җыенын үткәрергә.
4. Октябрьский авыл җирлегенең Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.
5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Октябрьский авыл җирлеге башлыгы Ш. Р. Азизов